| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Шарлиареминского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль**<br>**районы Шәрләрәмә авыл**<br>**җирлеге Советы** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь 2018 ел № 83

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2019 нче елга һәм 2020, 2021 нче план еллар чорына бюджеты турында карар проекты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 елларның план чорына бюджеты турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында » карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

1. Хуҗина Н.Н. – төркем җитәкчесе
2. Ахметшина Р.Ф. – төркем әгъзасы
3. Гайнетдинов М.С. – төркем әгъзасы
4. Халиуллина С.А.- төркем әгъзасы
5. Салихҗанова М.Р.- төркем әгъзасы

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре ТР, Сарман муниципаль районы,Шәрләрәмә авылы, Мәктәп урамы, 57 йорт адресына язмача җибәрелә дип билгеләргә.

5. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2019 нче елга һәм 2020, 2021 нче елларның планлы чорына бюджеты турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 нчы елның 5 нче декабрендә 14.00 сәгатьтә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы каравына 2018 елнын 12 декаберенә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN .RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина